**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 9 апрелендәге 1136 номерлы карары**

**1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгын, Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен, Яңа ел белән бәйле чараларны, бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгын, Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен, Яңа ел белән бәйле чараларны, бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру чорында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. чараларны әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне әлеге карарга 1, 2, 3, 4, 5 номерлы кушымталар нигезендә билгеләргә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. транспорт предприятиеләренә юлларны ябу һәм җәмәгать транспорты маршрутларын үзгәртү турында хәбәр итәргә;

1.2.2. вакытлы юл билгеләрен урнаштыру схемасын эшләргә һәм вакытлы юл билгеләрен урнаштыру һәм эшләп килүче юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.3. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы яшелләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) чаралар уздыру чорында ремонт-төзелеш эшләрен башкару графигына төзәтмәләр кертергә, чараларга әзерләнгәндә транспорт керү юлларын һәм парковка урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы эшләр башкарырга, чаралар уздырыла торган урыннарга якын урнашкан урам-юл челтәре объектларын, чаралар тәмамланганнан соң, җыештыруны тәэмин итәргә, халыкка мәгълүмат җиткерү өчен урам-юл челтәре участокларын ябу схемаларын яктырту баганаларында урнаштыруны килештерергә, Казан шәһәре Башкарма комитеты районнары администрацияләре (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карарның кушымталары нигезендә Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) массакүләм мәгълүмат чаралары аша Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләү кертелүе турында хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 9 апрелендәге
1136 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чараларны уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның 1 маенда,<br>2026 елның 2 маенда,<br>2026 елның 3 маенда,<br>2026 елның 4 маенда,<br>2026 елның 5 маенда,<br>2026 елның 6 маенда,<br>2026 елның 7 маенда (кирәк булганда)<br>16.00 сәгатьтән 23.30 сәгатькә кадәр | Меңьеллык мәйданында (шул исәптән Бауман урамы буенча, Профсоюз урамыннан Батурин урамына кадәр);<br>Кремль яр буе урамы буенча;<br>Декабристлар урамы буенча (Меңьеллык мәйданыннан алып Сибгат Хәким урамына кадәр);<br>Декабристлар урамы буенча (Комсомол урамыннан алып Меңьеллык мәйданына кадәр);<br>Ташаяк урамы буенча (Мәскәү урамыннан Меңьеллык мәйданына кадәр);<br>Уң як Болак урамы буенча (Меңьеллык мәйданыннан Чернышевский урамына кадәр);<br>Сул як Болак урамы буенча (Меңьеллык мәйданыннан Чернышевский урамына кадәр);<br>цирк һәм Үзәк стадион арасындагы юл |
| 2 | 2026 елның 29 апрелендә 00.00 сәгатьтән 2026 елның 10 маенда 24.00 сәгатькә кадәр<br>(кирәк булганда) | Үзәк стадион белән цирк арасындагы парковка<br>(227 нче зона) |
| 3 | 2026 елның 29 апрелендә 14.30 сәгатьтән 18.30 сәгатькә кадәр | Оренбург Тракты дублер-урамы (Оренбург Тракты урамындагы 172 номерлы йорт янәшәсендәге чыгу юлыннан «Примавера» торак массивына кадәр) |
| 4 | 2026 елның 8 маенда 18.00 сәгатьтән 2026 елның 10 маенда 03.00 сәгатькә кадәр | Бондаренко урамы буенча (Ямашев проспектыннан Маршал Чуйков урамына кадәр ике юнәлештә);<br>Волгоград урамы буенча (Бондаренко урамыннан Короленко урамына кадәр ике юнәлештә) |
| 5 | 2026 елның 9 маенда 7.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр<br>(кирәк булганда) | Ямашев проспекты буенча (Мусин урамыннан Короленко урамына кадәр ике юнәлештә);<br>Ямашев проспектындагы парковка (260 нчы зона) |

| | | |
|---|---|---|
| 6 | 2026 елның 8 маенда 16.30 сәгатьтән 2025 елның 10 маенда 08.00 сәгатькә кадәр | Меңьеллык мәйданында (шул исәптән Бауман урамы буенча,<br>Профсоюз урамыннан Батурин урамына кадәр);<br>Профсоюз урамы (Чернышевский урамыннан Бауман урамына кадәр);<br>Кремль яр буе урамы буенча;<br>Декабристлар урамы буенча (Меңьеллык мәйданыннан Сибгат Хәким урамына кадәр);<br>Декабристлар урамы буенча (Комсомол урамыннан алып Меңьеллык мәйданына кадәр);<br>Ташаяк урамы буенча (Мәскәү урамыннан Меңьеллык мәйданына кадәр);<br>Уң як Болак урамы буенча (Меңьеллык мәйданыннан Чернышевский урамына кадәр);<br>Сул як Болак урамы буенча (Меңьеллык мәйданыннан Чернышевский урамына кадәр);<br>цирк һәм Үзәк стадион арасындагы юл; К.Нәҗми урамы буенча;<br>Муса Җәлил урамы буенча |
| 7 | 2026 елның 9 маенда 08.30 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр | Карл Маркс урамы буенча (Горький урамыннан алып Лобачевский урамына кадәр);<br>Лобачевский урамы буенча (Зур Кызыл урамыннан Кремль урамына кадәр);<br>Кремль урамы буенча (Лобачевский урамыннан Беренче Май мәйданына кадәр);<br>Толстой урамы буенча (Большая Красная урамыннан Горький урамына кадәр);<br>Мөштәри урамы буенча (Большая Красная урамыннан Горький урамына кадәр);<br>Гоголь урамы буенча (Большая Красная урамыннан Горький урамына кадәр);<br>Жуковский урамы буенча (Большая Красная урамыннан Горький урамына кадәр);<br>Пушкин урамы буенча (Большая Красная урамыннан Горький урамына кадәр);<br>Театр урамы буенча (Большая Красная урамыннан Дзержинский урамына кадәр);<br>Профессор Нужин урамы буенча (Университет урамыннан Пушкин урамына кадәр);<br>Университет урамы буенча (Кремль урамыннан Профсоюз урамына кадәр);<br>Кремль урамы буенча (Лобачевский урамыннан Университет урамына кадәр);<br>Кави Нәҗми урамы буенча;<br>Муса Җәлил урамы буенча |
| 8 | 2026 елның 1 маенда 15.00 сәгатьтән 2026 елның 11 маенда 11.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Үзәк стадион янындагы парковка зонасы;<br>Әсгать Галимҗанов скверы янәшәсендәге җирле юл |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | 2026 елның 9 маенда 19.00 сәгатьтән 23.30 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Сибгат Хәким урамы буенча (Декабристлар урамыннан алып Абдулла Бичурин урамына кадәр ике юнәлештә дә) |
| 10 | 2026 елның 9 маенда 08.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр | Юдино микрорайоны:<br>Революция урамындагы 16 номерлы йортның 1 корпусыннан Ильич урамына кадәр,<br>Ильич урамындагы 19/43 номерлы йорттан Лейтенант Красиков урамына кадәр;<br>Лейтенант Красиков урамындагы 5/34 йорттан алып Бирюзовая урамы, 3 йортка кадәр |
| 11 | 2026 елның 1 маенда 08.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Воровский урамы буенча (Профессор Мөхәммәдьяров урамыннан Декабристлар урамына кадәр);<br>Воровский урамы һәм Декабристлар урамы ягыннан «Казан-2» тимер юл вокзалына килү юллары, шулай ук парковка зонасы һәм тимер юл вокзалы янында сквер белән вокзал бинасы арасындагы юл |
| 12 | 2026 елның 7 маенда, 2026 елның 8 маенда 00.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Театр урамы буенча (Большая Красная урамыннан Дзержинский урамына кадәр);<br>Ирек мәйданы |

____________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 9 апрелендәге
1136 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Россия көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар уздырганда Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның 12 июнендә 18.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр | Батурин урамы буенча (Карл Маркс урамыннан Кремль дамбасына кадәр) |
| 2 | 2026 елның 12 июнендә 18.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр | Большая Красная урамы буенча (Миславский урамыннан Батурин урамына кадәр);<br>Мецьеллык мәйданыннан Батурин урамына төшү юлы |
| 3 | 2026 елның 12 июнендә 00.00 сәгатьтән 2026 елның 13 июнендә 12.00 сәгатькә кадәр | Сибгат Хәким урамы буенча (Декабристлар урамыннан Әпсәләмов урамына кадәр), «Казан» гаилә үзәге янындагы территория (парковка зонасы);<br>Бондаренко урамы буенча (Солдат урамыннан Сибгат Хәким урамына кадәр) |

___________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 9 апрелендәге
1136 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның 27 августында 00.00 сәгатьтән 2026 елның 31 августында 24.00 сәгатькә кадәр (кирәк булган очракта) | Сибгат Хәким урамы буенча (Декабристлар урамыннан Әпсәләмов урамына кадәр); «Казан» гаилә үзәге янындагы территория (парковка зонасы); Бондаренко урамы буенча (Солдат урамыннан Сибгат Хәким урамына кадәр) |
| 2 | 2026 елның 28 августында 20.00 сәгатьтән 2026 елның 31 августында 11.00 сәгатькә кадәр | Шиһабетдин Мәрҗани урамы (Татарстан урамыннан Фатыйх Кәрим урамына кадәр); Каюм Насыйри урамы (Татарстан урамыннан Фатыйх Кәрим урамына кадәр); Зәйни Солтан урамы (Габдулла Тукай урамыннан Каюм Насыйри урамына кадәр) |
| 3 | 2026 елның 30 августында 18.00 сәгатьтән 2026 елның 30 августында 24.00 сәгатькә кадәр (шәһәр җәмәгать транспорты маршрутларыннан кала) | Батурин урамы (Большая Красная урамыннан Кремль яр буе урамына кадәр ике юнәлештә дә); Меңьеллык мәйданыннан Батурин урамына төшү юлы |
| 4 | 2026 елның 24 августында 07.00 сәгатьтән 2026 елның 31 августында 18.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Кремль урамы (Астрономия урамыннан Беренче Май мәйданына кадәр), шул исәптән Профсоюз урамына кадәр Иван төшү юлы |
| 5 | 2026 елның 24 августында 07.00 сәгатьтән 2026 елның 31 августында 18.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Федосеев урамы (Батурин урамыннан Япеев урамына кадәр) |
| 6 | 2026 елның 1 маеннан 2026 елның 15 октябренә кадәр | Тихомирнов урамын һәм Петербург урамын тоташтыручы автомобиль юллары |

____________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның  9 апрелендәге
1136 номерлы карарына
4 номерлы кушымта

**Яңа ел бәйрәм чараларын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның 18 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2027 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | С.Хәким урамы буйлап ике якка да (Декабристлар урамы белән кисешкән урыннан Әпсәләмов урамы белән кисешкән урынга кадәр)<br>«Казан» гаилә үзәге янындагы парковка зонасы;<br>Бондаренко урамы буенча (Солдат урамыннан Сибгат Хәким урамына кадәр) |
| 2 | 2026 елның 18 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2027 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Бондаренко урамы буенча ике якка да (Сибгат Хәким урамындагы 3 номерлы торак йорттан Сибгат Хәким урамына тоташкан урынга кадәр) |
| 3 | 2026 елның 18 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2027 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Зәйни Солтан урамы (Мәрҗани урамыннан Каюм Насыйри урамына кадәр) |
| 4 | 2026 елның 18 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2027 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Мәрҗани урамы (Татарстан урамыннан Фатыйх Кәрим урамына кадәр) |
| 5 | 2026 елның 18 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2027 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Кремль урамы (Чернышевский урамыннан Беренче Май мәйданына кадәр) |

_______________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 9 апрелендәге
1136 номерлы карарына
5 номерлы кушымта

**Бөек татар шагыйре Г.Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында чаралар әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның 26 апрелендә 07.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр | Театр урамы буенча (Карл Маркс урамыннан алып Дзержинский урамына кадәр) |

______________________